# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**30 март 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында" карары

нигезендә 2024 елның 30 мартында 14.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән протокол төзелде. Гражданнар җыенына түбәндәге сораулар тәкъдим ителде.

«Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Ләшәү Тамак авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ләшәү Тамак авылында Ленин урамы, буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм транспортлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Ләшәү Тамак авылында триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; договор нигезендә хезмәтенә түләү) МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Ләшәү Тамак авылы сабантуй мәйданына материал сатып алу ); ?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 154 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар жыенында «РИЗА» позициясе өчен 98 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл жирлегенең Ләшәү Тамак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныrга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныrга.

2. Түбәндәге сораулар буенча :

«Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Ләшәү Тамак авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ләшәү Тамак авылында Ленин урамы, буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм транспортлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Ләшәү Тамак авылында триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; договор нигезендә хезмәтенә түләү) МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Ләшәү Тамак авылы сабантуй мәйданына материал сатып алу ); арарны кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче — И.З.Хабибуллин